ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 октября 2026 года

Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 1 апреля 2005 года № 60-ЗРТ «Об объектах культурного наследия в Республике Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 2 июля 2015 года № 51-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 4 (I часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть); 2016, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 38 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I), № 40 (часть I); 2020, № 1 (часть I); 2021, № 20 (часть I), № 93 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 48 (часть I), № 96 (часть I); 2025, № 29 (часть I); 2026, № 32 (часть I) следующие изменения:

1) часть 3 статьи 3 дополнить пунктом 8^1 следующего содержания:

«8^1) принятие решения об исключении объекта культурного наследия регионального значения, объекта культурного наследия местного (муниципального) значения из единого государственного реестра объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации по согласованию с федеральным органом охраны объектов культурного наследия;»;

2) часть 2 статьи 4 дополнить пунктами 9^{11} – 9^{13} следующего содержания:

«9^{11}) создание научно-методического совета по сохранению и государственной охране объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации (далее – региональный научно-методический совет);

9^{12}) утверждение положения о региональном научно-методическом совете;

9^{13}) утверждение порядка рассмотрения региональным научно-методическим советом проектной документации на проведение работ по сохранению объекта культурного наследия, включенного в единый государственный реестр объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов

Российской Федерации, или выявленного объекта культурного наследия, указанных в подпункте 2 пункта 3^2 статьи 45 Федерального закона;»;

3) в части 1 статьи 5:

а) в пункте 8 слово «выдача» заменить словом «предоставление»;

б) дополнить пунктами 8^1 – 8^3 следующего содержания:

«8^1) создание научно-методического совета по сохранению и государственной охране объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации (далее – муниципальный научно-методический совет);

8^2) утверждение положения о муниципальном научно-методическом совете;

8^3) утверждение порядка рассмотрения муниципальным научно-методическим советом проектной документации на проведение работ по сохранению объекта культурного наследия, включенного в единый государственный реестр объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации, указанного в подпункте 3 пункта 3^2 статьи 45 Федерального закона;»;

4) в части 4 статьи 10 слова «и согласования» исключить;

5) дополнить статьей 11^1 следующего содержания:

«Статья 11^1. **Исключение объекта культурного наследия из единого государственного реестра объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации**

1. Решение об исключении объекта культурного наследия из единого государственного реестра объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации принимается Кабинетом Министров Республики Татарстан на основании заключения государственной историко-культурной экспертизы по согласованию с федеральным органом охраны объектов культурного наследия:

в отношении объекта культурного наследия регионального значения – по представлению органа охраны объектов культурного наследия Республики Татарстан;

в отношении объекта культурного наследия местного (муниципального) значения – по представлению органа охраны объектов культурного наследия Республики Татарстан на основании обращения органа местного самоуправления.

2. Кабинет Министров Республики Татарстан в течение пяти рабочих дней со дня принятия решения об исключении объекта культурного наследия регионального значения, объекта культурного наследия местного (муниципального) значения из единого государственного реестра объектов культурного наследия (памятников истории и культуры) народов Российской Федерации направляет копию такого решения в федеральный орган охраны объектов культурного наследия.».

Статья 2

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей установлены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункты 1 и 5 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 23 января 2027 года.

3. Абзац четвертый пункта 2, подпункт «а» и абзац четвертый подпункта «б» пункта 3, пункт 4 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 марта 2027 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 октября 2026 года
№ 68-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 октябрендә
кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2025, № 29 (I өлеш); 2026, № 32 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 8^{1} пункт өстәргә:

«8^{1}) региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы белән килештереп, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул итү;»;

2) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 9^{11} – 9^{13} пунктлар өстәргә:

«9^{11}) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу һәм дәүләт саклавы буенча фәнни-методик совет (алга таба – региональ фәнни-методик совет) төзү;

9^{12}) региональ фәнни-методик совет турындагы нигезләмәне раслау;

9^{13}) Федераль законның 45 статьясындагы 3^{2} пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни

мирас объектын яисә ачыкланган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга проект документациясен региональ фәнни-методик совет тарафыннан карау тәртибен раслау;»;

3) 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 8 пунктта татарча текст үзгәрешсез кала;

б) түбәндәге эчтәлекле 8^1 – 8^3 пунктлар өстәргә:

«8^1) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу һәм дәүләт саклавы буенча фәнни-методик совет (алга таба – муниципаль фәнни-методик совет) төзү;

8^2) муниципаль фәнни-методик совет турындагы нигезләмәне раслау;

8^3) Федераль законның 45 статьясындагы 3^2 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга проект документациясен муниципаль фәнни-методик совет тарафыннан карау тәртибен раслау;»;

4) 10 статьяның 4 өлешендә «һәм килештерү» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле 11^1 статья өстәргә:

«11^1 статья. **Мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру**

1. Мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карар, мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органы белән килештереп, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасы бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан түбәндәгечә кабул ителә:

региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектына карата – Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча;

җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектына карата – җирле үзидарә органы мөрәҗәгате нигезендә Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тәкъдиме буенча.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә мондый карарның күчермәсен мәдәни мирас объектларын саклауның федераль органына җибәрә.».

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 5 пунктлары 2027 елның 23 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацы, 3 пунктының «а» пунктчасы һәм «б» пунктчасының дүртенче абзацы, 4 пункты 2027 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 29 октябрь
№ 68-ТРЗ